ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы турында» Декретка кул куелуга 100 ел тулу хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинның «ТАССРның 100 еллыгы: үткәне һәм бүгенгесе» докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

1920 елның 27 маендагы «Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы турында» Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советының уртак Декреты – XX йөзьеллыкта җөмһүриятебезнең тарихи юлын билгеләгән мөһим сәяси-хокукый акт ул.

1920 елның 25 июнендә хакимият вәкаләтләрен Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасының Вакытлыча Революция Комитетына тапшыру булган. Бу дата республикабыз төзелү көне булды да. Әлеге вакыйга – татар милләтенең һәм республикада яшәгән барлык халыкларның меңьеллык дәүләтчелегенең алга таба үсешендә мөһим адым.

Яңа республика тормышының башлангыч чоры катлаулы булды – Гражданнар сугышыннан калган җимереклек, 1921 – 1922 еллар ачлыгы, коллективлаштырудан һәм күпләгән репрессияләрдән килгән зыян. Ләкин, югалтуларга һәм авырлыкларга карамастан, республикада зур яңа эшләр алып барылды: сәнәгатьтә яңа тармаклар барлыкка килде, шәһәрләр һәм авыллар инфраструктурасы яхшырды.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының (алга таба – ТАССР) Верховный Советына 1938 елның 26 июнендәге беренче сайлаулар, әһәмиятле вакыйга булып, республиканың сәяси системасын ныгытуга зур өлеш кертте. Яңа закон чыгару органы профессионал идарәче кадрлар әзерләү урыны булды, анда җәмгыятьнең хокукый аңы формалашты.

Халкыбызның күтәренке рухы, хезмәттәге батырлыгы һәм аяусызлыгы нәтиҗәсендә бу еллар эчендә республика алга киткән сәнәгате, фәнни һәм мәдәни куәте булган тулы кыйммәтле совет автономиясенә әверелде.

Ил өчен җитди сынау Бөек Ватан сугышы булды. 700 мең ватандашыбыз фронтка китте, шуларның яртысы сугыштан кире әйләнеп кайтмады, ә 200 дән артык ул һәм кызга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Республикага уннарча хәрби предприятие, фәнни-тикшерену, белем бирү учреждениеләре эвакуацияләнде, алар, кыска вакыт эчендә җитештерүне көйләп, Җиңүгә үзләреннән зур өлеш кертте.

Сугыштан соңгы еллар, бик авыр еллар булуга карамастан, ТАССРның социаль-икътисадый яктан үсеш чоры булды. Без нефть чыгаруны үзләштерү һәм Кама буенда нефть-химия җитештерү комплексы төзелеше, КАМАЗның аякка басу һәм Татарстанның илдә эре машина төзелеше үзәгенә әверелү чорын хәтерлибез. Бу казанышлар һәм тупланган кыйммәтләр республиканың мөстәкыйльлеге артуны, СССР составында аның хокукый статусы киңәюне таләп итте.

Үзгәртеп кору чорындагы яңа сәяси курс гражданнарның активлыгы һәм милли үзаң үсешенә кискен этәргеч бирде. Килеп туган шартларда Татарстан, шартнамәчел яшәешне үзләштерүдә һәм үстерүдә, федерализм принципларын яклауда беренчеләрдән булып, мөстәкыйльлекне ныгыту юлына басты.

Илебез өчен киеренке чорда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары демократик үзгәртеп коруларда әйдәп баручы һәм аларның гаранты булды, ә депутатлар корпусы үзенең киеренке, системага салынган хезмәте белән яңа Татарстан дәүләтчелеген булдыруга үзеннән зур өлеш кертте.

Республикабыз узган юлга борылып карасаң, тулы ышаныч белән шуны әйтергә була: төп кыйммәтләре гражданнар арасындагы татулык һәм халыклар дуслыгы булган бүгенге Татарстан җәмгыятенең ныклы нигезе 1990 нчы елларда салынды.

Республиканың төп байлыгы – аның уртак максатлар өчен тыныч вакытта да, сугыш елларында да берләшә алучы күпмилләтле халкы. Татарстан тарихы моны ышандырырлык итеп раслады. Республиканың чын тарихы бары тик халык тарафыннан гына язылды!

Икътисадый казанышларның сизелерлек нәтиҗәләре федераль үзәкнең актив ярдәмендә, мәгарифне, мәдәниятне, сәламәтлек саклауны үстерүнең, инфраструктура һәм торак төзелешен кызыксындыруның күләмле программаларын гамәлгә ашырып, социаль өлкәне яңартырга мөмкинлек бирә. Бу елларда халык яшәешенең төрле өлкәләрендәге мәсьәләләрне уңышлы хәл итүнең уникаль тәҗрибәсе тупланды. Һичшиксез, монда һәр татарстанлының да керткән өлеше бар. Татарстан Республикасы алга таба да безнең уртак илебезнең – Россия Федерациясенең икътисадый, мәдәни һәм рухи үсешенә үзенең тиешле өлешен кертүне дәвам итәр дип ышанабыз.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинның «ТАССРның 100 еллыгы: үткәне һәм бүгенгесе» докладын хупларга.

2. Республика халкына Татарстанның дәүләтчелеген төзүдә һәм үстерүдә, аның социаль-икътисадый, фәнни-техник, рухи һәм мәдәни куәтен ныгытуда актив катнашкан өчен рәхмәт белдерергә.

3. ТАССР Верховный Советы, Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы, Татарстан Республикасы Югары Советы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары корпусының Татарстан Республикасы тарихының бөтен чорларында да аның төзелүенә һәм эзлекле үсешенә керткән өлешенең әһәмиятен билгеләп үтәргә.

4. Инициативаларны хупларга һәм ТАССР төзелүгә 100 ел тулуга багышланган федераль һәм республика чараларында якыннан катнашырга.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, барлык милек рәвешендәге оешмаларга, граждан җәмгыяте институтларына һәм яшьләр оешмаларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

республика тарихының данлы сәхифәләрен һәм вакыйгаларын, шулай ук ТАССР һәм Татарстан Республикасы үсешенә зур өлеш керткән аның эшлеклеләренең истәлеген, массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртып, мәңгеләштерү буенча комплекслы эшне дәвам итәргә;

үсеп килүче буын арасында республиканың атаклы казанышларын пропагандаларга;

татар телен һәм мәдәниятен, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә ярдәм итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарына киләсе утырышта, аңа сугыш һәм хезмәт ветераннарын чакырып һәм аларның республиканың социаль-икътисадый үсешенә керткән өлешен билгеләп, Татарстанның узган йөзьеллык тарихы турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә.

7. Республиканың иҗат берлекләренә Татарстан Республикасының бай тарихы тематикасын эшләүне һәм тормышка ашыруны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә республика һәм аның күпмилләтле халкы тарихын өйрәнү һәм популярлаштыру буенча фәнни-тикшеренү эшен активлаштырырга.

9. Әлеге карарны республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 27 мае
№ 426-VI ДС